КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 27 декабрь г.Казань № 1425

«2023 елга Татарстан Республикасында гражданнарга торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү» программасын раслау турында

Татарстан Республикасында гражданнарны һәркем сатып алырлык торак белән тәэмин итү һәм дәүләт программаларының гамәлдәге кайбер чаралары кысаларында «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру чараларын финанслашуны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «2023 елга Татарстан Республикасында гражданнарга торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү» программасын расларга.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасында гражданнарга торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү» программасын раслау турында» 2021 ел, 27 декабрь, 1293 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Бу карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин